| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«НИЖНЕЧЕРШИЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ТҮБӘН ЧЫРШЫЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

**2022 елның 1 июне** **№ 10**

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлеге Советының 2016 елның 27 апрелендәге 12 номерлы карары белән расланган Түбән Чыршылы авыл җирлегендә хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлеге Советының 2016 елның 27 апрелендәге 12 номерлы карары белән расланган Түбән Чыршылы авыл җирлегендә хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

8 пунктның 3 пунктчасында «,акцияләр» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Түбән Чыршылы авылы, Түбән Чыршылы авылы административ бинасында-Үзәк урам, 105 йорт, балалар бакчасы бинасында -Совет урамы, 8 йорт, Үзәк урам, 23 йорт буенча, «АФ-Спартак» ҖЧҖ идарәсе бинасында-Совет урамы, 2 йорт , Югары Чыршылы авылында-авыл клубы бинасында-Горная урамы, 27 йорт, Мордва Ивановкасы авылында - Совет урамы, 13 йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

«Түбән Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы, Совет рәисе Н.Я.Хәйруллина